КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 5 ноябрь г.Казань № б-2250

Татарстан Республикасы Президентының «Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул итүенең 1100 еллыгын бәйрәм итү турында» 2021 елның 4 июнендәге ПУ-434 номерлы Указын тормышка ашыру кысаларында оештыру мәсьәләләрен оператив хәл итү максатларында:

1. 2022 елда Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул итүенең 1100 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү кысаларында гамәлгә ашырыла торган чараларны координацияләү буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – эшче төркем) төзергә һәм аның составын (боерыкка теркәлә) расларга.

2. Эшче төркемгә 2022 елда Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул итүенең 1100 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү кысаларында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм муниципаль берәмлекләренең, оешмалары һәм учреждениеләренең үзара хезмәттәшлеген координацияләүне тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары В.Г.Шәйхразыевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 5 ноябрь, б-2250 нче
боерыгы белән расланды

2022 елда Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул итүенең
1100 еллыгын әзерләү һәм үткәрү кысаларында гамәлгә ашырыла торган
чараларны координацияләү буенча ведомствоара эшче төркем
составы

| | |
|---|---|
| Шәйхразыев Васил Габтелгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, ведомствоара эшче төркем җитәкчесе |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, ведомствоара эшче төркем җитәкчесе урынбасары |
| Лоцманова Елена Игоревна | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары секретариатының баш киңәшчесе, эшче төркем секретаре |

Ведомствоара эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Әхмәдиев Роза Шәйхәйдәр кызы | югары белем бирүче «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Башарова Альбина Альберт кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсенә караган Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү секторы баш киңәшчесе |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Денисов Максим Сергеевич | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Дирзизов Альберт Ривкат улы | Татарстан Республикасы Президенты Департаментының Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек итү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Заһидуллина Дания Фатыйх кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе вице-президенты |
| Низамова Ләйсән Гаптелхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сәмигуллин Камил Искәндәр улы | Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте – үзәкләштерелгән дини оешма рәисе (килешү буенча) |
| Сөләйманов Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәйруллин Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Хәкимҗанов Ленар Сәетҗан улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Шиһабетдинов Дамир Равил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары ярдәмчесе. |